ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

с. Большие Меми

ел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-

22.05.2019 — № 15

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге генераль планын әзерләү турында**

Территорияне тотрыклы үстерүне, инженер, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне тәэмин итү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 24, 25 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы нигезендә,

**Карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге генераль планы проектын әзерли башларга.
2. Проектны эшләү вакытын 6 ай билгеләргә.
3. Олы Меми авыл җирлеге Башкарма комитеты сәркатибе - Сальцинова А. А. -физик һәм юридик затларның проектны әзерләү тәртибе, вакыты һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәрен кабул итү һәм карауны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Югары Осланмуниципаль районы**
**Олы Меми авыл җирлеге**
**Башлыгы** **Г. А. Фомина**